Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Кәләй авыл җирлегенең Урман Кәләй авылында
гражданнар җыенынә тиҗәләре турында
КАРАР

18 ноябрь 2019 ел №1

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1. 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы,«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенең Урман Кәләй авылында гражданнар җыенының беренче, икенче, өченче,дүртенче, бишенче этаплары тавыш бирү нәтиҗәләре (нәтиҗәләре) турында» 2019 елның 18 ноябрендәге беркетмәсе, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенең Урман Кәләй авылында гражданнар җыеныкарар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенең Урман Кәләй авылында 2019 елның 18 ноябрендә узган халык җыенын үткәрелгән дип таныргa, җыенның нәтиҗәләре - дөрес.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Кәләй авыл җирлегенең Урман Кәләй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:торак пункт юлларын норматив хәлгә китерү?»мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип таныргa

3.Халык җыены нәтиҗәләрен «Альметьевский вестник» газетасында, Кәләй тимер юл станциясе бистәсе, Железнодорожная урамы, 38б йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

Урман Кәләй
авыл җирлеге башлыгы Л.Н. Фәләхиев